**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

«05» октябрь, 2022 ел

№ 709

2023 елга Питрәч муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге «Татарстан Республикасы сәнгать-эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 854 номерлы карары һәм Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты Уставы нигезендә Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. 2023 елга расларга:

- Питрәч муниципаль районы муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар;

-сәнгать-эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,65 күләмендә төзәтмәләр коэффициенты.

2. Питрәч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасында әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.С. Шәйхесламовка йөкләргә.

Муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе А.В.Хәбибуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе карары белән расланды
«__» _______ 2022 № ____

**Питрәч муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар (1 укучыга елына сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | жиде еллык уку вакыты | иртә һөнәри ориентация |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 79714 | 91055 | 116878 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 42126 | | 37425 | 89801 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 88953 | 73250 | 268494 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 37395 | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 81803 | 78547 | 126162 |
| Эстрада джаз сәнгате | авыл җирлеге | 123091 | | 118014 | | 193471 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 63434 | | 59063 | 58977 | 88859 |